**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**IV ЧАКЫРЫЛЫШ LIII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 93**

*Югары Табын авылы* *"24" нче март, 2025 нче ел*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районың Түбән Табын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1 нче кушымта).

2.Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә (2 нче кушымта), әлеге карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (muslumovo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Югары Табын, Түбән Табын, Тугаш, Тегермәнлек, Тамьян, Кызыл Яр авыллары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:

Югары Табын ав., Тукай ур., 19Б бинасы (мәдәният йорты бинасы);
Түбән Табын ав., Мәктәп ур., 40А йорты (интернат -мәктәп бинасы);
Тугаш ав., Вахитов ур., 10А йорты (мәдәният йорты бинасы);
Тегермәнлек ав., Һ. Такташ ур., 30 йорт (шәхси йорт);
Тамьян ав., Комсомол ур., 20Б йорты (авыл клубы бинасы);
Кызыл Яр ав., М. Җәлил ур., 2 йорт (шәхси йорт).

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районының**
**Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы** **Р.Ш. Кыяметдинов**


Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының
Түбән Табын авыл җирлеге Советының
93 нче карарына 1 нче кушымта
«24» март 2025 ел

**Мөслим муниципаль районы “Түбән Табын авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча сайлау округлары СХЕМАСЫ**

| № п/п | Сайлау округының номеры һәм иseme | Сайлау округына керүче торак пунктлары | Сайлау округына керүче урам исемнәре | Сайлау округына керүче йорт номерлары | Сайл аучыл ар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Югары Табын № 1 | Югары Табын ав. | Тукай ур. | №№ 1 – 19А<br>№№ 2 – 22 | 90 |
| | | | Кооператив ур. | №№ 1 – 29, 33А<br>№№ 2 – 26 | |
| 2 | Югары Табын № 2 | Югары Табын ав. | Кооператив ур. | №№ 31 – 73А<br>№№ 28 – 56А | 92 |
| | | | Татарстан ур. | тулысынча | |
| 3 | Тамьян № 3 | Тамьян ав. | тулысынча | | 92 |
| | | Югары Табын ав. | Тукай ур. | №№ 21 – 47<br>№№ 24 – 60 | |
| 4 | Түбән Табын № 4 | Түбән Табын ав. | Мәктәп ур. | тулысынча | 88 |
| | | | Бакча ур. | тулысынча | |
| 5 | Тегермәнлек № 5 | Түбән Табын ав. | Яшьләр ур. | тулысынча | 86 |
| | | Тегермәнлек ав. | тулысынча | | |
| 6 | Тугаш № 6 | Тугаш ав. | Вахитов ур. | №№ 1 – 35А<br>№№ 2 – 32 | 84 |
| 7 | Тугаш № 7 | Тугаш ав. | Пушкин ур. | полностью | 83 |
| | | | Вахитов ур. | №№ 37 – 53<br>№ 34 | |
| | | Кызыл Яр | тулысынча | | |

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының
Түбән Табын авыл җирлеге Советының
93 нче карарына 2 нче кушымта
«24» март 2025 ел

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең бер мандатлы округлары схемасының график сурәтләнеше



Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының
Түбән Табын авыл җирлеге Советының
93 нче карарына 3 нче кушымта
«24» март 2025 ел

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең бер мандатлы округлары схемасының график сурәтләнеше

